Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ерепкино авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

17 ноябрь 2020 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлегенең Ерепкино авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Ерепкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Ерепкино авылы чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу;
- Ерепкино авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу;
- гражданнардан зиратларны төзекләндерүгә һәм карап тотуга 2016 елда җыелган һәм 2017 елда 55000 сум күләмендә финансланган үзара салым акчаларын Ерепкино авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлауга һәм карап тотуга юнәлдерерү.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Х. Шәйхетдинов

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы: Р.Х. Шәйхетдинов